**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯҢА ШАШЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**НОВОШАШИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ**
**АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422008 Республика Татарстан Атнинский район с. Новые Шаши. Тел. 3-23-23

КАРАР

01 ноябрь 2024 ел №2

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Яңа Шашы авыл җирлеге **Чембулат** торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законының 25.1, 56 статьясы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Уставы белән **карар чыгарам:**

1. 2024 елның 13 нче ноябренә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чембулат торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.1.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чембулат торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 13 ноябрь 2024 ел 13.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны – Чембулат авылы, Тынычлык ур., 24 нче йорт, авыл клубы;

1.2 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итергә:

- 2024 елның 05 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Яңа Шашы авылы, Яшьләр урамы, 13 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Чембулат торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;
- Чембулат торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итергә;

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2025 елда Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чембулат торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш,

500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1. Торак пункт территориясен төзекләндерү.
   (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм алар янындагы территорияне төзекләндерү; ( Чембулат авылында обелиск әзерләү һәм урнаштыру (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү))

"РИЗА" "КАРШЫ"

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталыда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Яңа Шашы авылы Яшьләр урамы 13 нче йорт адресы буенча урнашкан стендка урнаштырырга.
4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы: М.С.Сабирҗанов